СОВЕТ ВАХИТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.28, д. им. М. Вахитова,
422575

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВАХИТОВ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Үзәк ур., 28нче йорт, М. Вахитов исем авылы,
422575

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ | КАРАР

18.12.2019 | № 71-321

д. им. М. Вахитова

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-

Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлегенең
2020 елга һәм 2021-2022 елларның планлы чорына бюджеты турында

Статья 1

1. 2019 елга Вахитов авыл җирлеге (алга таба – җирлек) бюджетының төп характеристикаларын расларга:
1) җирлек бюджеты керемнәренең гомуми күләме 2530,08 мең сум;
2) җирлек бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 2530,08 мең сум.
3) җирлек бюджеты дефициты 0 мең сум.
2. 2020, 2021 еллар план чорына җирлек бюджетының төп характеристикасын расларга:
1) 2021 елга җирлек бюджеты керемнәренең гомуми күләме 2482,90 мең сум һәм 2022елга 2514,84 мең сум күләмендә;2) җирлек бюджеты чыгымнарының гомуми күләме:
- 2021 елга 2482,90 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 62,07 мең сум күләмендә;
- 2022 елга 2514,84 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 125,74 мең сум күләмендә.
3) 2021 елга җирлек бюджеты дефициты 0 мең сум һәм 2022 елга 0 мең сум күләмендә.
3. Җирлек бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын билгеләргә:
- 2020 елга әлеге карарга 1нче кушымта нигезендә;
- 2021 һәм 2022 еллар план чорына әлеге карарның 2нче кушымта нигезендә.

Статья 2

1. 2021 елның 1 гыйнварына җирлекнең бурыч йөкләмәләре буенча эчке муниципаль бурычның иң югары чиген 0 мең сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә билгеләргә.
2. 2022 елның 1 гыйнварына җирлекнең бурыч йөкләмәләре буенча эчке муниципаль бурычның югары чиген 0 мең сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә билгеләргә.
3. 2023 елның 1 гыйнварына җирлекнең бурыч йөкләмәләре буенча эчке муниципаль бурычның югары чиген 0 мең сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә билгеләргә.

4. Җирлекнең муниципаль бурычының чикле күләмен билгеләргә:
- 2020 елда – 0 мең сум күләмендә;
- 2021 елда – 0 мең сум күләмендә;
- 2022 елда – 0 мең сум күләмендә.

Статья 3
Җирлек бюджетында 2020 елга керемнәрнең фаразлана торган күләмнәрен әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә, 2021 һәм 2022 еллар план чорына әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

Статья 4
2020 елда һәм 2021 һәм 2022 елларның планлы чорында җирлек бюджетына күчерелү салымнар түләгәннән соң калган һәм башка мәҗбүри түләүләрдән калган муниципаль унитар предприятиеләр табышының бер өлешен кертү 2019, 2020 һәм 2021 елларга алынган чиста табышның 30 проценты күләмендә башкарыла дип билгеләргә.

Статья 5
1. Җирлек бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә расларга.
2. Җирлек бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 6 нчы кушымта нигезендә расларга.

Статья 6
1. Бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгымнар төрләре төркемнәре буенча җирлек бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бүлүне расларга:
- 2020 елга әлеге карарга 7 нче кушымта нигезендә;
- 2021 һәм 2022 еллар план чорына әлеге карарга 8 нче кушымта нигезендә.
2. Күрсәтелгән чыгымнарның ведомство структурасын түбәндәгечә расларга:
- 2020 елга әлеге карарга 9 нчы кушымта нигезендә;
- 2021 һәм 2022 еллар план чорына әлеге карарга 10 нчы кушымта нигезендә.

Статья 7
Югары Ослан муниципаль районы бюджетыннан алына торган җирлек бюджетында бюджетара трансфертларны исәпкә алырга:
- 2020 елда әлеге карарга 11 нче кушымта нигезендә 1202,18 мең сум күләмендә.
- 2021 елда әлеге карарга 12 нче кушымта нигезендә 1242,30 мең сум һәм 2022 елда 1260,94 мең сум күләмендә

Статья 8
Җирлек муниципаль хакимияте органнары 2020 елда һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорында муниципаль хезмәткәрләр һәм бюджет өлкәсенең башка оешмалары хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

Статья 9
2020 елда җирлек милкендә булган һәм бюджет мәдәният һәм сәнгать, сәламәтлек саклау, мәгариф учреждениеләренә, шулай ук архив учреждениеләренә оператив идарәгә тапшырылган мөлкәтне арендага бирүдән кергән керемнәр җирлек бюджеты

керемнәре составына кертелә һәм әлеге карар нигезендә бюджет йөкләмәләрен үтәүгә файдаланыла дип билгеләргә.

Статья 10
Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешүләр нигезендә җирлек бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыра.

Статья 11
2020 елның 1 гыйнварына җирлек исеменнән төзелгән товарлар белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга, әлеге муниципаль контрактларның шартлары нигезендә 2019 елда түләнергә тиешле хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактларның җирлек бюджеты калган акчасы тиешле карар кабул ителгән очракта, 2020 елда әлеге максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

Статья 12
Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Статья 13
Әлеге карар Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырылырга тиеш.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге
башлыгы Ф.Р. Каримов